# ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ТИҢДӘШ КИСӘКЛӘР
## (Г.Тукайның тууына 126 ел )

*И туган тел  и  матур тел*
*Әткәм-әнкәмнең теле.*

***И туган тел, и матур тел,***

***Әткәм-әнкәмнең теле.***

**Тиңдәш кисәкләр бер үк сорауга җавап бирә һәм бер үк сүзгә карый.**



**Туган тел.**

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.
Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

*Габдулла Тукай.*

***1.Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.***
***Нәрсәдән бу?-мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген !***

***(“Бәйрәм бүген”)***

***2. Күп тә үтми, бу Бала куйды тәмамлап дәресене,***
***Куйды бер читкә җыеп дәфтәр, китапны- барысыны.***

***(“Эш беткәч уйнарга ярый”)***

***3.Театр- яктылыкка, нурга илтә,***
***Кире юлга җибәрми, уңга илтә.***

***(“Театр”)***

**Барлык җөмлә кисәкләре дә тиңдәшләнә ала.**

# Туган авыл

- Тау башына салынгандыр безнең авыл,
- Бер чишмә бар,  якын безнең авылга ул;
- Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
- Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән…
- Истән чыкмый монда минем күргәннәрем.
- Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
- Абый белән бергәләшеп, кара җирне
- Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.

**Тиңдәш кисәкләр сөйләмне матур, яңгырашлы итә.**

***Җәй көне. Эссе һавада мин суда ..., ...;***
***Чәчрәтәм, ..., ..., башым белән суны ... .***
***Шул рәвешле бер сәгать ярым кадәрле уйнагач,***
***Инде шаять бер сәгатьсез тирләмәм дип ...,***
***Йөгереп чыктым судан, тиз – тиз ... өс – башым;***
***Куркам үзем әллә нидән, юк янымда .... .***

***Анда бик салкын вә бик ... түгел, ... һава***
***... дә вакытында исеп, ... да вакытында ...***
***Урманында кып – кызыл кура җиләк тә ... ....***
***Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.***
***Бик хозур, рәт – рәт тора, гаскәр кеби, ..., нарат;***
***Төпләрендә ятканым бар, хәл ..., күккә ... .***

**Тиңдәш кисәкләр санау интонациясе һәм теркәгечләр ярдәмендә бәйләнә.**

# Безнең гаилә

Әткәй, әнкәй,мин, апай,әби,бабай һәм бер песи-
Безнең өйдә без җидәү: безнең песи- җиденчесе.
Бергә ашый,чәйтэчә,безнең лә бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар; өйне тычкан явыздан саклый ул.

Г.Тукай

**Тиңдәш кисәкләр:**

- ***бер үк сорауга җавап булып килә,***
- ***бер үк сүзгә карый,***
- ***санау интонациясе, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнә,***
- ***бөтен җөмлә кисәкләре булып килә ала,***
- ***сөйләмне матур, яңгырашлы итә.***

Өй эше:

1 нче төркемгә:   Г.Тукайның тиңдәш кисәкләр  кергән берәр шигырен  язырга.

2 нче теркемгә: Тиңдәш кисәкләр кертеп, “Рәхмәт сиңа, Тукай абый” исемле хикәя төзеп язырга.